«**Раслыйм**»
Татарстан Республикасы
Әлмәт мунииипаль районы
муниципаль бюджет гомуми
белем учреждениесе
«Мәмәт төп гомуми бирү мәктәбе»
директоры ________ М.А. Гилязова
«_20_» ___12___2023 ел

**«Килешенде»**
Татарстан Республикасы
Әлмәт мунииипаль районы
мәгариф идарәсе җитәкчесе
__________ И.А. Павловская

«_20_» ___12___2023 ел

## Социалистик Хезмәт Герое, Татарстан АССРның атказанган төзүчесе Саттаров Рәшит Саттар улына багышланган муниципаль бәйге НИГЕЗЛӘМӘСЕ

### I. Гомуми нигезләмә

Әлеге нигезләмә Социалистик Хезмәт Герое, Татарстан АССРның атказанган төзүчесе, Әлмәт шәһәренең мактаулы гражданины, ташчы, Әлмәт районы Мәмәт авылында туып үскән Саттаров Рәшит Саттар улына багышланган “**Хезмәт батырлары белән көчле илебез**” муниципаль бәйге үткәрүнең тәртибен билгели.

### II. Бәйгенең максат һәм бурычлары

2.1. Бәйгенең максаты Р.С.Саттаровның хезмәт юлын, илебез төзелешенә керткән фидакарь хезмәтен өйрәнүне, авылдашыбызның исемен халыкка таныту, популярлаштыруны, шулай ук эзләнү эшчәнлеге аша укучыларның иҗади һәм тикшеренү сәләтләрен ачуны, мөстәкыйль эшләргә өйрәтүне күздә тота.
2.2. Бәйгенең бурычлары:
- укучыларны үз туган ягыңның тарихын, күренекле шәхесләрен өйрәнүгә җәлеп итү;
- үсеп килүче буында патриотик хисләр, туган якка мәхәббәт, милләтебезнең батыр уллары белән горурлану хисләре тәрбияләү;
- Рәшит Саттаров үрнәгендә яшь буынга хезмәт тәрбиясе бирү.

### III. Бәйгенең оештыручылары

3.1. Бәйгенең оештыручылары:
- “Татарстан Республикасы Әлмәт мунииипаль районы мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе;
- Татарстан Республикасы Әлмәт мунииипаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Мәмәт төп гомуми белем бирү мәктәбе”;
3.2. Оештыру комитеты “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе, Әлмәт мунииипаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Мәмәт төп гомуми белем бирү мәктәбе” укытучылар, укучылар һәм киң җәмәгатьчелек игътибарына мәгълүмат хатлары, мәктәпнең “ВК” рәсми социаль челтәре аша белдерү урнаштыра; бәйге эшләрен җыюны һәм жюри эшчәнлеген оештыра, бүләкләү эшен оештыра.

### IV. Эксперт төркеме һәм жюри

4.1. “Татарстан Республикасы Әлмәт мунииипаль районы мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе боерыгы нигезендә, бәйгегә килгән эшләрне бәяләү өчен

эксперт төркеме һәм жюри төзелә. Экспертлар һәм жюри әгъзалары тәҗрибәле мәгариф ветераннары, күренекле җәмәгать эшлеклеләре, мәктәп җитәкчеләре һәм укытучылар арасыннан сайлана.
4.2. Бәйгегә килгән эшләр эксперт төркеме һәм жюри әгъзалары тарафыннан, алдан әзерләнгән критерийлар нигезендә, *10 баллы* система буенча бәяләнә. Баллар куелган бәяләү битендә һәр эксперт теркәлә, шуннан соң, әлеге бәяләү кәгазе оештыру комитетына тапшырыла.

Жюри нәтиҗәләренә карата дәгъвалар кабул ителми.

## V. Катнашучылар, аларның эшләренә таләпләр

5.1 Бәйгедә Әлмәт муниципаль районы мәктәпләре, лицей, гимназия укучылары, укытучылар, китапханәчеләр, музей җитәкчеләре катнаша ала.
5.2. Укучыларның иҗади эшләре түбәндәге яшь категорияләре буенча кабул ителә:
- 1-4 сыйныфлар;
- 5-9 сыйныфлар;

5.3. Бәйге түбәндәге юнәлешләр буенча үтә:
1) “Кеше - хезмәт белән матур” темасына нәфис сүз бәйгесе (1-9 сыйныфлар).
2) “Булыр кеше эшеннән билгеле” эзләнү характерындагы фәнни эшләр бәйгесе (5-9 сыйныфлар).
3) “Эш кешене төзәтә, ялкаулык - боза” рәсем бәйгесе (1-4 сыйныфлар)
4) Укытучылар, китапханәчеләр, музей җитәкчеләре өчен “Матур әдәбиятта хезмәт темасы”на методик лаборатория.
5.4. Бәйгегә эшләр татар телендә кабул ителә. Бер укучы 2-3 юнәлештә берьюлы катнаша ала.
5.5. “Кеше – хезмәт белән матур” юнәлешендә укучылар татар язучыларының әсәрләре буенча шигырь яки чәчмә әсәрдән өзекне яттан сәнгатьле укырга әзерләнә. Чәчмә әсәрдән өзекнең логик яктан тәмамланган төсмер алуы шарт. Башкару вакыты 3 минуттан артмаска тиеш. Катнашучы бәйгенең оештыру комитетына заявка-анкетага видеоязманың сылтамасын куеп җибәрә (язманың вертикаль, AVI яки MP3 форматында, Яндекс диск, яки Гугл дискка урнаштырылган булуы шарт).
5.6. “Булыр кеше эшеннән билгеле” юнәлешенә укучылар туган төбәкнең осталарына, тырыш хезмәт ияләренә багышланган фәнни эш башкара. Реферат форматындагы, фәнни эш таләпләре үтәлмәгән эшләр кабул ителми. Фәнни эшне презентация, төрле кушымталар белән баетырга мөмкин.
5.7. “Эш кешене төзәтә, ялкаулык – боза” юнәлешендә укучылар Әлмәт язучылар берлеге язучыларының әсәрләре буенча рәсем ясыйлар. Эшнең сканкүчермәсе заявка-анкета белән бергә җибәрелә. Формат А4. (Рәсемне башкаручының исем-фамилиясе, тулы яше, сыйныфы, җитәкченең исем-фамилиясе күрсәтелә).
5.8. Укытучылар татар әдәбиятында эш, хезмәт, тырышлык темасын яктырткан әсәрләр буенча иҗади эшләре белән методик лабораториядә катнаша ала: дәрес эшкәртмәсе, осталык дәресе, технологик карта, дәрестән тыш уку, уку грамоталылыгын үстерү.
Катнашучылар заявка-анкета һәм эшләрен оештыру комитетына юллый. Күләме чикләнмәгән. (Таләпләр: текст реакторы Word; - бит размеры А4; полялар: өске, аскы, уң як – 1,5 см, сул як – 2 см.; шрифт: Times New Roman, размер – 14; юллар арасы – 1,0; бит киңлеге буенча тигезләргә).

## VI. Бәйгене үткәрү тәртибе

6.1. Бәйгедә катнашучылар 2024 нче елның 11 нче мартына кадәр эшләрне һәм заявка-анкетаны (кушымта) оештыру комитетының lyalya-sitdikova@mail.ru электрон почтасына җибәрә. Хатның темасы: "Хезмәт батырлары". Нәтиҗәләр белән 18 март көнне, мәктәп сайтында таныша аласыз.

Беренче тапкыр үткәрелү сәбәпле, бу уку елында бәйге дистанцион форматта үза. Барлык эшләр белән мәктәпнең рәсми сайтында "Хезмәт батырлары" (муниципаль конкурс) https://edu.tatar.ru/almet/mametyevo/sch/page5356814.htm рубрикасында таныша аласыз.

6.2. Бәйгенең җиңүчеләре һәм призёрлары Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсенең дипломнары белән бүләкләнә. Барлык катнашучыларга сертификатлар җибәрелә. Дипломнар, сертификатлар заявка-анкетада күрсәтелгән адреска юллана.

Белешмәләр өчен телефоннар: Әлмәт муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе "Мәмәт төп гомуми белем бирү мәктәбе"нең туган тел һәм әдәбият укытучысы Ситдикова Ләлә Насыйх кызы 89178837886.

КУШЫМТА

"Хезмәт батырлары белән көчле илебез" бәйгесендә
катнашу өчен заявка-анкета

| | |
|---|---|
| Катнашучының Ф.И.Ә исеме | |
| Эш урыны / уку урыны | |
| Сыйныфы, туган көне | |
| Юнәлеше | |
| Эшнең темасы, әсәрнең авторлары | |
| Яндекс диск, яки Гугл дискка сылтама<br>(1 юнәлеш өчен) | |
| Җитәкченең<br>Ф.И.Ә исеме, телефоны | |